ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ

КАРАР № 8

Урыссу ш.т.п. 30.03 2022 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2019 елның 23 декабрендәге 23 номерлы "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында» Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2019 елның 23 декабрь, №19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «К» пунктчасын өстәргә:

к) йорт биләмәләре территориясендә үсә торган утыртылган агачларны тиешле хәлдә тотарга, авария куркынычы булган һәм корыган ботакларны кисәргә, авария куркынычы булган һәм корыган агачларны кисәргә.

1.2. 6.2 пунктында «П» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

п) йорт биләмәсенә якын урындагы территориядә клумбалар, чәчәк түтәлләре, декоратив ихата һәм кече архитектура формалары сыйфатында автомобиль покрышкаларын файдалану.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының http://javo.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының кеше хокуклары, законлылык һәм хокук тәртибе комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе -
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Урыссу шәһәр
тибындагы поселогы Башлыгы А. Ә. Шәфигуллин